СОВЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

11 декабрь 2018 ел г.Мензелинск № 5

**Минзәлә муниципаль районының бүләкләү комиссиясе турында**

Гражданнарның, предприятие коллективларының, учреждение һәм оешмаларның муниципаль район алдындагы ирешелгән уңышларын тану, кеше һәм гражданнарның хокукларын һәм иреген яклауга, муниципаль төзелеш, социаль-икътисадый, мәдәни үсеш, Минзәлә муниципль районының чәчәк атуына, хезмәткә стимул бирү һәм җәмәгать тормышында активлыкны һәм җирле үзидарә үсешенә юнәлтелгән шәхси эшчәнлеген бүләкләүне тану максатларында, Минзәлә муниципаль район Советы

КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Расларга:

- Муниципаль район бүләкләре (награда) белән бүләкләү буенча документларны тикшергәндә килеп туган документларны һәм бәхәсле мәсьәләләрне тикшерү буенча бүләкләү комиссиясе составы (кушымта №1)

- бүләкләү комиссиясе турында Положение (кушымта №2).

2. Гамәлдәге Карар 2019 елның 1 гыйнварыннан көченә керә.

3. Гамәлдәге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Минзәлә муниципаль район Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Совет рәисе А.Ф. Салахов

Кушымта №1
Минзәлә муниципаль
район Советы карарына
________________________№_______

**Минзәлә муниципаль районының Бүләкләү комиссиясе составы**

| | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Вазифасы |
|---|---|---|
| 1. | Хәбибуллина Эльвира Васил кызы | ТР Минзәлә муниципаль район Советы аппараты җитәкчесе (комиссия рәисе) |
| 2. | Токарев Марк Олегович | ТР Минзәлә муниципаль район Башлыгы ярдәмчесе (комиссия рәисе урынбасары) |
| 3. | Фассахова Эльвира Наил кызы | ТР Минзәлә муниципаль район Советының оештыру бүлеге начальнигы (комиссия сәркатибе) |
| 4. | Гатина Айгөл Гомәр кызы | ТР Минзәлә муниципаль район Башкарма Комитеты Җитәкчесе урынбасары |
| 5. | Бикеева Нэля Габдулла кызы | Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары |
| 6. | Сәгыйрова Ләлә Рәмис кызы | ТР Минзәлә муниципаль район Советының кадрлар бүлеге начальнигы |
| 7. | Леванов Александр Дмитриевич | ТР Минзәлә муниципаль район Советы депутаты |
| 8. | Зыятдинов Заһир Мирзагабдулла улы | ТР Минзәлә районы ветераннар Советы рәисе |
| 9. | Хәлимова Гөлфия Котдус кызы | ТР Минзәлә муниципаль районы Иҗтимагый советы рәисе |
| 10. | Мусина Айгөл Хәниф кызы | ТР Минзәлә районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең финанс-икътисад бүлеге начальнигы |

Кушымта №2
Минзәлә муниципаль район
Советы карарына

11.12.2018ел №5

# Бүләкләү комиссиясе Положениесе турында

## 1. Гомуми положениеләр

1.Бүләкләү комиссиясе Минзәлә муниципаль районында төзелә һәм коллегиаль һәм киңәшүче орган булып тора.

1.2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары, Минзәлә муниципаль район Уставы, шулай ук гамәлдәге Положениегә таянып эш итә.

1.3. Бүләкләү комиссиясе бүләкләү материалларына җәмәгатьчелек бәясен бирү, казанышларга объектив бәя билгеләү һәм бүләкләүгә тәкъдим ителгән затларның Минзәлә муниципаль район үсешенә керткән өлешен ачыклау өчен булдырыла.

1.4. Комиссия үз эшен беренчел профсоюз оешмасының профсоюз комитеты белән берлектә оештыра.

1.5. Комиссияне район Советы аппараты җитәкчесе (алга таба – Комиссия рәисе), ә ул булмаганда, район башлыгы ярдәмчесе (алга таба – комиссия рәисе урынбасары) җитәкли.

## 2. Комиссия эшен оештыру

2.1. Комиссия булдыру һәм аның эшчәнлеген туктату турындагы карар район Башлыгы тарафыннан кабул ителә.

Комиссия җәмәгать башлангычы шартларында эшли.

2.2. Комиссиянең персональ составы район Башлыгы Карары белән раслана.

2.3 Комиссия составына җирле үзидарә органнары вәкилләре, депутат корпусы, предприятие һәм оешма җитәкчеләре, беренчел профсоюз оешмалары рәисләре, учреждение җитәкчеләре, шулай ук җәмәгать оешмалары вәкилләре керә.

2.4. Комиссия материалларны алдан тикшерүне башкара һәм бүләкләү турында тәкъдимнәрне Минзәлә муниципаль район Башлыгына кертә, шулай ук Минзәлә муниципаль район Башлыгы бүләкләре (награда) белән бүләкләү буенча документларны тикшергәндә килеп туган бәхәсле мәсьәләләрне карый.

Бүләкләү комиссиясенә тапшырыла торган документлар:

- бүләкләүне нигезләп, предприятие, оешма, учреждение җитәкчесенең үтенеч язуы;

- җитештерү, фәнни, хезмәт, иҗтимагый-тәрбияви эшчәнлеккә яисә бүләкләнүгә тәкъдим ителгән башка казанышларга характеристика (формасы бирелгән);

- нинди хосусыйлык формасында булуына карамастан, предприятие, учреждение һәм оешмаларның җитәкчелек составы затларын тәкъдим иткәндә, салымнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар турында, соңгы өч ел эчендә предприятиенең төп икътисадый һәм җитештерү күрсәткечләре

динамикасы турында белешмәләр (белешмәләр 3 ай гамәлдә була).

2.5. Бүләкләү комиссиясе 20 көн эчендә бүләкләү материалларын тикшерә, карар проектларын әзерли.

Зарурлык туганда, комиссия утырышлары комиссия рәисе яисә аның урынбасары тарафыннан уздырыла.

2.6. Утырышта катнашучылар саны барлык әгъзаларның яртысыннан күбрәк булган очракта, комиссия утырышы хокуклы санала.

2.7. Комиссия утырышларындагы карарлар катнашучыларның күпчелек тавыш бирүе аша кабул ителә.

Карарлар беркетмәләр белән рәсмиләштерелә, аларны сәркатип алып бара, комиссия рәисе кул куя.

2.8. Комиссия әгъзалары тарафыннан карар кабул иткәндә тавышлар тигез булса, комиссия рәисе карар кабул итә.

2.9.Бүләкләү материаллары килешенгән, расланган һәм рәсмиләштерелгәннән соң, район Башлыгы боерыгы әзерләнә.

2.10. Эш башкару һәм утырышка документларны әзерләү комиссия сәркатибе тарафыннан башкарыла.

## 3. Комиссия вәкаләтләре

3.1.Үз утырышларында җирле үзидарә органнары вәкилләре, депутат корпусы, предприятие һәм оешма җитәкчеләре, беренчел профсоюз оешмалары рәисләре, учреждение җитәкчеләре, шулай ук җәмәгать оешмалары вәкилләренең тәкъдимнәрен тыңларга һәм тикшерергә тиеш.

3.2. Бүләкләүгә тәкъдим итү буенча мәгълүмати һәм башка материалларны соратып алырга тиеш.

3.3. Бүләкләү өчен кандидатларны тәкъдим итәргә тиеш.

## 4. Йомгаклау положениеләре

4.1. Карарлар һәм бүләкләү материаллары комиссия сәркатибендә саклана торган аерым делога тегелә.

4.2. Бүләкләр тантаналы шартларда тапшырыла.